ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУСЛЮМОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӨСЛИМ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15.09.20203 Мөслим авылы № 403

**Балигъ булмаган гражданнарга карата опека һәм попечительлек өлкәсендә дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентларын раслый торган Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты карарларын гамәлдән чыгару турында**

Гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан балигъ булмаган гражданнарга карата опека һәм попечительлек өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын раслый торган карарларны үз көчләрен югалткан дип санарга:

1.1. - Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 23 июнендәге 332 номерлы «Балигъ булмаган балага караган күчемсез милекне читләштерү буенча килешүләрне гамәлгә ашыруга алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Административ регламентын раслау турында»гы карары;

1.2. - Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының 2020елның 23 июнендәге 333 номерлы «Балигъ булмаганны тулысынча эшкә яраклы дип игълан итү (эмансипация) турында карар кабул итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Административ регламентын раслау турында»гы карары;

1.3. - Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 23 июнендәге 335 номерлы «Ундүрт яшькә җитмәгән баланың исемен һәм (яки) фамилиясен үзгәртүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Административ регламентын раслау турында» карары;

1.4. - Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 23 июнендәге 338 номерлы «Балигъ булмаган бала исеменнән сатып алуның өстенлекле хокукыннан баш тартуга алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Административ регламентын раслау турында»гы карары;

2. Әлеге карарны Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга http://pravo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль-мәдәни үсеш буенча урынбасары М.Р. Бәдретдиновага йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **И.Ф. Салихҗанов**